**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2025 Балык Бистәсе штп. № 30пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.11.2010 №247пи карары белән расланган Физик зат каршында акчалата рәвештә түләргә тиешле гавами йөкләмәләрне үтәү һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү буенча «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 13.07.2024 ел, №177-ФЗ Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.11.2010 №247пи карары белән расланган Физик зат каршында акчалата рәвештә түләргә тиешле гавами йөкләмәләрне үтәү һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү буенча «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә:

1.1) 2 пунктта «индексация күләмендә яисә билгеләнгән тәртибе булган» сүзләрен «индексация күләмендә һәм (яисә) билгеләнгән тәртибе булган»сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 6 пунктның 6 пунктчасында", шул исәптән бюджет исәбен алып бару, бюджет хисабын төзү һәм бирү буенча " сүзләрен өстәргә.»;

1.3) 12 пунктны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә:

«12. Учреждение Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары түләлеше турында еллык, квартал һәм айлык хисапны төзү һәм тапшыру өчен

финанс органы билгеләгән тәртиптә бюджет хисабын төзи һәм җирле үзидарә органына тапшыра.»;

1.4) 13 пунктта «җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов